**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмә.**

2023 елның 6 марты

Ачык тыңлаулар Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге Башлыгы инициативасы белән үткәрелде, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге башлыгының 2023 елның 31 гыйнварындагы 15-РС номерлы карары белән билгеләнде.

Татар Янтыгы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында 2023 елның 31 гыйнварындагы 15-РС номерлы карары Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

1. 2023 елның 10 февралендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегенең рәсми сайтында;
2. 2023 елның 10 февралендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);
3. 2023 елның 10 февралендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;
4. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында

Ачык тыңлауларда катнашучылар ачык тыңлаулар уздыру сроклары, проектның мәгълүмати материаллары, проект материаллары экспозициясен уздыру сроклары һәм урыны, катнашучылар җыелышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында, проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр бирү тәртибе турында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 6 февралендәге 731/исх номерлы белдерүе белән хәбәр ителделәр.

2023 елның 6 февралендәге 731/исх номерлы ачык тыңлаулар башлану турында хәбәр басылып чыкты (халыкка җиткерелде):

5. 2023 елның 10 февралендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегенең рәсми сайтында;
6. 2023 елның 10 февралендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы территориясендә таратыла торган «Кама ягы»(«Камская новь») газетасында (мәгълүмат хәбәрләрен бастырып чыгару юлы белән);

7. 2023 елның 10 февралендә Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча;

8. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында

Ачык тыңлауларны оештыручы: Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе.

Рәислек итүче: Карсалов Алексей Петрович – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы - Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе рәисе урынбасары.

Ачык тыңлаулар секретаре: Прокофьева Любовь Ивановна – Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Татар Янтыгы авыл җирлегендә Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен әзерләү комиссиясе секретаре.

Ачык тыңлауларның нәтиҗәләре турында бәяләмә 2023 елның«5»мартындагы Татар Янтыгы авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре проекты буенча ачык тыңлаулар беркетмәсе нигезендә төзелде.

Ачык тыңлауларда 8 кеше катнашты.

Ачык тыңлауларда катнашучылардан проект буенча искәрмәләр һәм тәкъдимнәр кермәде.

Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре:

1. Халык тыңлауларын үткән дип таныргa;
2. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Татар Янтыгы авыл Татар Янтыгы проектын, 2023 елның«5»мартындагы ачык тыңлаулар беркетмәсен һәм бәяләмәне, проектны йомгаклап раслау өчен, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советына җибәрергә.

Ачык тыңлаулар рәисе ___________________________ Карсалов А.П.

Ачык тыңлаулар секретаре _________________________ Прокофьева Л.И.